СОВЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

20.07.2023 г.Зеленодольск № 297

Зеленодольск муниципаль районы Советының 2019 елның 26 апрелендәге 378 номерлы карары белән (Зеленодольск муниципаль районы Советының 2019 елның 8 августындагы 413 номерлы, 2022 елның 28 октябрендәге 210 номерлы карарларына кертелгән үзгәрешләре белән) расланган «Зеленодольск муниципаль районы финанс-бюджет палатасы» муниципаль учреждениесе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Зеленодольск муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» муниципаль учреждениесе җитәкчесе урынбасары Т.М. Ламбинаның Зеленодольск муниципаль районы Советының 2019 елның 26 апрелендәге 378 номерлы карары белән (Зеленодольск муниципаль районы Советының 2019 елның 8 августындагы 413 номерлы, 2022 елның 28 октябрендәге 210 номерлы карарларына кертелгән үзгәрешләре белән) расланган «Зеленодольск муниципаль районы финанс-бюджет палатасы» муниципаль учреждениесе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында мәгълүматын тыңлап фикер алышканнан соң , 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды**:

1. Зеленодольск муниципаль районы Советының 2019 елның 26 апрелендәге 378 номерлы карары белән (Зеленодольск муниципаль районы Советының 2019 елның 8 августындагы 413 номерлы, 2022 елның 28 октябрендәге 210 номерлы карарларына кертелгән үзгәрешләре белән) расланган «Зеленодольск муниципаль районы финанс-бюджет палатасы» муниципаль учреждениесе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 5.1 пунктының беренче абзацына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Палата җитәкчесе вазыйфасына кандидатларның квалификация таләпләренә туры килүен тикшерү Татарстан Республикасы финанс органы катнашында башкарыла. Күрсәтелгән тикшерүне уздыруда Татарстан Республикасы финанс органының катнашу тәртибе «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына 3 нче кушымта белән билгеләнә.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматы рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

**Зеленодольск муниципаль районы**
**Башлыгы, Совет рәисе** **М. П. Афанасьев**

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ИНН 1648017831 КПП 164801001
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ